БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ ҺӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ
ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №20—21 (7037—7038) | 17 февраль, 1990 ел. ШИМБӘ | Бәясе 3 тиен.

**Мәскәүдә СССР Верховный Советы сессиясе үзенең эшен дәвам иттерә.**

# Депутатлыкка кандидатлар белән очрашу

## Иң лаеклыларны сайлыйк

Елаур урта мәктәбенең Ленин залына авыл кешеләре җыелган. Бирәдәгеләрнең сүзләре эшлекле. Әмма алар күбрәк халык депутатларының чираттагы Съезды турында әңгәмә алып баралар. Анда күтәрелгән проблемаларны тикшерәләр. Аларны үзләре, хуҗалыклары белән чагыштыралар. Аларны тыңлап торгач, халкыбызның торгынлык вакытындагы йокысыннан уянуына сөенәсең. Әйе, безнең халкыбыз авыр күтәрелә, ә аннан соң инде аны туктатам димә.

Яшьләре белән төрле кешеләрне мәктәпкә нәрсә китергән соң? Моны аңлатуы җиңел. Алар ТАССР Верховный Советына халык депутатлыгына кандидат, КПСС өлкә комитеты секретаре Ә. Г. Булатов белән очрашуга килгәннәр.

Очрашуны «Знамя Октября» колхозы партия оешмасы секретаре М. М. Сафин ачты һәм сүзне кандидатның ышанычлысы, АПО рәисе Х. Х. Гатинга бирде.

Иптәш Гатин сайлаучыларны кандидатның биографиясе, аның хезмәт һәм җәмәгать эшчәнлеге белән таныштырып, барысын да сайлаулар көнендә үзләренең тавышларын Ә. Г. Булатовка бирергә чакырды.

Аннан соң халык депутатлыгына кандидат республикада азык-төлек программасын тормышка ашыруда нәрсәләр эшләнүе турында сөйләде, киләчәктә бу бурычны хәл итү буенча билгеләнгән чаралар белән таныштырды. Кандидатның сайлау алды платформасы КПСС өлкә комитеты платформасы белән аваздаш. Аннан соң иптәш Булатов залдан әйтелгән күп төрле сорауларга җаваплар бирде.

Менә авыл укытучысы П. С. Гаязова сүз ала. Ул үзенең туган авылы проблемалары турында сөйли. Барыннан да элек алар—газ кертү, юлларга асфальт җәю, буалар төзү.

—Болар авыл халкын борчыган төп проблемалар. Әлеге бурычларны үтәп чыксаң, башкалары әкрен генә үтәлер сыман, —диде һәм кандидатка да бәя бирде. Тыйнак, күп вәгъдә бирми, ә биргәннәрен үтәр дигән өмет бар. Сүзгә бик оста түгел. Әмма аңарда игелек көче бөркелеп тора. Бик чуар составлы аудитория белән тиз уртак тел тапты.

Зоотехник Р. З. Каеваның чыгышы укытучыныкына аваздаш иде. Шушындый ук наказлар, шулар өстенә авылда торак йортлар төзү, фермаларны механикалаштыру.

—Ә. Г. Булатов күп сөйләшми, ләкин төгәл итеп әйтә. Эшлеклелеге әллә каян күренеп тора, ирексездән ышаныч белән аңа тартыласың, —диде ул. Һәм барлык сайлаучыларны Әхмәтҗан Галимҗановичка тавыш бирергә чакырды.

Укытучы П. П. Иванова, фельдшер-акушерка Л. М. Ерепова һәм башкаларның чыгышы да дикъкать белән тыңланды.

Очрашуның азагында КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов чыгыш ясады. «Безнең язмышыбыз үзебезнең кулда. Халык депутаты итеп намуслы кешене күрсәтү үзе бер бәхет. Аны сайлап ялгышмабыз дип уйлыйм», диде ул.

Шул ук көнне иптәш Булатов «Лесная Поляна» колхозы һәм «Мамык» совхозы хезмәтчәннәре белән очрашты.

* * *

15 февральдә Ә. Г.Булатов Ульянов исемендәге, Синдряков исемендәге колхозлар,«Тәрнәс»,«Сөлчә» совхозлары сайлаучылары белән очрашты.

**Г. ХӘЛИУЛЛИНА.**



«Тәрнәс» совхозында Михаил Степанович Андреевны белмәгән кеше юк. Менә инде өч дистә ел рәттән терлекчелектә эшли ул. Икенче товарлыклы-сөтчелек фермасында аны тырышлыгы, ярдәмчел булуы өчен хөрмәт итәләр.

Рәсемдә: терлекче М. Андреев.

Л. Шәмсуаров фотосы.

* * *

15 февраль көнне район культура йортында 127 нче Лениногорск милли-территориаль сайлау округы буенча РСФСР халык депутатлыгына кандидатлар белән очрашу булды.

Очрашуда бу округ буенча теркәлгән 7 кандидат катнашты. Алар— Ринат Хәлиуллович Мөслимов —«Татнефть» берләшмәсенең баш геологы, Әлмәт шәһәре хезмәт коллективларыннан, Вәлиәхмәт Нурмөхәммәтович Хуҗин — Чистай суднолар ремонтлау заводы слесаре, Чистай шәһәре хезмәт коллективларыннан, Илһам Шәймәрдәнович Шәймәрдәнов —Азнакай районының «Авангард» колхозы тракторчысы, Азнакай шәһәр партия комитеты пленумыннан, Нил Вәлиевич Гыйрфанов — Әлмәт батырма насослар заводы партия оешмасы секретаре, тору урыныннан, Иван Георгиевич Жжонов —нефть һәм химия промышленносте профсоюзының Татарстан өлкә комитеты председателе, профсоюзның өлкә комитеты пленумыннан, Владимир Павлович Лютахин — Лениногорск нефть техникумы укытучысы, шул техникум укытучылары һәм укучылары коллективыннан, Ринат Сафиевич Мөхәммәдиев —Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, Актаныш районы колхозлары вәкилләре коллективыннан.

Очрашуда депутатлыкка кандидатларның ышанычлылары аларның тормыш юллары, кешелек сыйфатлары белән таныштырдылар һәм үз кандидатларын яклап тавыш бирергә өндәделәр.

Депутатлыкка кандидатлар итеп күрсәтелгән иптәшләр исә, үз чиратында, платформаларының нигезен тәшкил иткән положениеләр, шул исәптән тормыш позицияләре белән таныштырдылар һәм залдан бирелгән сорауларга җаваплар бирделәр.

**Ф. ГАЛИМОВА.**

## Нәтиҗәләр яхшы

Дуңгызлар симертү буенча хуҗалыкара берләшмә коллективы еллык планнарны һәм кабул ителгән йөкләмәләрне срогыннан алда үтәү өчен аеруча киеренкелек белән эшли.

Елның беренче аенда операторлар Фәрит Хәмидуллин, Валентина Храмова, Анатолий Захаров, Фәнил Хәмидуллин, эшчеләрдән Валентина Маркова һәм Любовь Галимова аеруча яхшы нәтиҗәләргә ирештеләр. Алар үзләре карый торган дуңгызлардан 496—475 әр грамм уртача тәүлеклек артым алдылар.

**В. КУЗЬМИНА.**

x x x

Соңгы елларда товарлыклы-сарыкчылык фермасы коллективы күркәм нәтиҗәләргә ирешә. Бигрәк тә уңган сарык караучылар Минтаһир Әбделвәлиев, Вәгыйзь Юнысов, Хәмзә Рәхмәтуллин һәм Галимулла Кәлимуллин үз группаларындагы малларның көр-таза булып үсүләре өчен бар тырышлыкларын куялар.

**Г. САДЫЙКОВА.**

Муса Җәлил исемендәге колхоз.

## Кызу мич янында

Күңелдә бәйрәм. Ул хезмәтеңне яхшы итеп башкарганда була. Менә шундый күптән көтелгән бәйрәм Норлат икмәк пешерүчеләренә дә килде. Аеруча киеренкелек һәм ритм белән эшләп, алар гыйнварь ае планнарын уңышлы үтәделәр. Планда каралган 220 тонна урынына предприятие 252 тонна продукция җитештерде. Тәүлегенә 8 тоннага якын икмәк пешерелде. 72 мең сумлык продукция реализацияләнде яки план 102,9 процентка үтәлде. Ай буена икмәкнең сыйфатыннан зарланучылар булмады.

Әйтергә кирәк, безнең продукциянең сыйфатына кагылышлы факторлар бик күп. Бу, барыннан да элек, онның һәм башка компонентларның— ягулыкның, суның, бүлмәнең температурасына бәйле. Беренче урында кешеләрнең эшкә мөнәсәбәте, үз бурычларына намуслы карашы да тора.

Икмәк пешерүчеләрнең хезмәте җиңел түгел. Шуның өчен дә бирәдә кадрлар еш алмашына. Күпләрне өч сменалы эш, план артыннан куудагы киеренкелек канәгатьләндерми. Әйтергә кирәк, даими рәвештә бер генә мич эшләп торды, ә шәһәрләр, авыллар һәр көн саен, һәм сәгать саен бездән икмәк көтте. Ай саен авылга 48 тоннага якын пешкән ипи озатыла. Безнең продукциянең күп кулланучылар— Ульянов исемендәге, Хафизов исемендәге, «Восход», Синдряков исемендәге, «Игенче», Муса Җәлил исемендәге колхозлар һәм «Рассвет» совхозы.

Безнең завод бригада подрядында эшли. Барлыгы 4 бригада бар. Беренче аңлау эшкә яхшы булышлык итә. Январь аенда Лилия Водолевская һәм Минҗиһан Вәлиәхмәтова бригадалары аеруча оешканлык белән һәм җитештерүчән эшләделәр.

Коллективның үз проблемалары, авырлыклары да җитәрлек. Аның иң кыены — чимал китерүләрен, он төялгән вагоннарның килүен зур борчылу белән көтү. Алар күпчелек вакытта я соңга калалар, я сортлары бертөрле була.

Шундый чаклар да бар: гел югары сорт ясә арыш оны гына җибәрәләр. Әйтерсең лә, производство белән без идарә итмибез, ә шартлар безнең белән идарә итә.

Шулай да коллективның кәефе күтәренке. Елның беренче аендагы уңышлар кешеләргә көч-куәт өстәде. Икмәк миче бер генә сәгатькә дә суынмый. Бирәдә һәрчак кызу.

**Р. АНАНЬЕВА,** икмәк заводы экономисты.

# 1990 елның 4 марты—халык депутатларын сайлаулар көне

## Татарстан АССРга халык депутатлыгына безнең кандидат

### 228 нче Мамык сайлау округы буенча халык депутатлыгына кандидат

# Әхмәтҗан Галимҗанович Булатов



Әхмәтҗән Галимҗанович Булатов 1937 елда Татарстан АССРның Тәтеш шәһәрендә туа. 1963 елдан КПСС члены. Милләте буенча татар.

Әхмәтҗан Галимҗанович урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Н. Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария институтына укырга керә. 1960 нчы елда, аны тәмамлаганнан соң, Бөгелмә шәһәрендә нәсел эше буенча дәүләт станциясе директоры итеп билгеләнә. Энергияле, яшьләр белән аралашучы белгечне 1961 елда комсомол эшенә күчерәләр, ул ВЛКСМның Бөгелмә шәһәр комитетының икенче секретаре итеп сайлана. Тагын бер ел үткәч, оештыру сәләтен күреп, аны Бөгелмә колхоз-совхоз производство идарәсе буенча ВЛКСМ өлкә комитетының комсоргы итеп сайлыйлар. Бу идарәләр бетерелгәч, ул республика авыл хуҗалыгы министрлыгында өлкән зоотехник булып эшли. 1967 елда аны КПСС өлкә комитетының авыл хуҗалыгы бүлегенә инструктор итеп күчерәләр.

1970 елда Ә. Г. Булатов кабат авыл хуҗалыгы министрлыгына эшкә кайта. Ул ике ел дәвамында терлекчелек һәм нәсел эше бүлеге начальнигы— ТАССР авыл хуҗалыгы министры урынбасары вазифасын башкара. Шуннан соңгы елларда республика совхозлар производство берләшмәсе начальнигының беренче урынбасары булып эшли. 1975 елда Әхмәтҗан Галимҗанович яңадан ТАССР авыл хуҗалыгы министрының терлекчелек буенча урынбасары итеп билгеләнә. 1978 елда КПСС өлкә комитетына эшкә кабат күчерелә. Авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире урынбасары булып эшли, 1980 елда исә шушы бүлекнең мөдире итеп раслана. 1985 елда ул КПСС өлкә комитеты секретаре, бюро члены итеп сайлана һәм бүгенге көнгә кадәр шул хезмәтен башкара.

Әхмәтҗан Галимҗанович һәр тармакта үзен авыл хуҗалыгы производствосын яхшы белүче, югары квалификацияле, эрудицияле белгеч итеп таныта. Оештыру, авыл хезмәтчеләрен билгеләнгән бурычларны үтәүгә туплый алу сәләте эштә ачыла. Ул үткән сайлауларда ТАССР Верховный Советы депутаты итеп сайлана. Хезмәттәге уңышлары өчен Әхмәтҗан Галимҗанович «Почет Билгесе» ордены, «В. И. Ленин тууга 100 ел тулу уңаеннан фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнә.

Синдряков исемендәге, Ульянов исемендәге, «Чишмә», «Комбайн» колхозы колхозчылары аны 228 нче Мамык сайлау округы буенча ТАССР халык депутатлыгына кандидат итеп күрсәттеләр.

## Ә. Г. Булатовның сайлау алды платформасының төп положениеләре

Сайлаучы иптәшләр! Гражданин һәм коммунист буларак, мин КПССның XXVII съезды, XIX Бөтенсоюз партия конференциясе эшләгән, СССР халык депутатлары Съездлары һәм СССР Верховный Советы кабул иткән законнарны, үзгәртеп кору бурычларын гамәлгә ашыруны партия һәм халык алдында торган беренче чираттагы бурычым итеп саныйм.

Үзгәртеп коруларны тормышка ашыру— экономика өлкәсендә реаль яңарышларга ирешү дигән сүз. Бу мәсьәләдә халык хуҗалыгын үстерүнең социаль проблемаларына өстенлек бирү, халыкның үсә барган ихтыяҗларын канәгатьләндерү мөһим бурыч булып тора.

Минем сайлау алды программам КПСС өлкә Комитетының 1989 елның декабрендә кабул иткән өлкә партия оешмасы платформасы белән авазлаш. Аның мөһим пункты булып азык-төлек проблемасын хәл итү тора. Соңгы елларда тулаем Татарстан АССР, шулай ук Октябрь районы буенча да ит, сөт, йомырка һәм башка төр продуктлар җитештерү юнәлешендә кайбер үсешкә ирешелде. Әмма аларның күбесенә дефицит үзен сиздерә. Бу проблемаларны хәл итүдә халыкны туклану продуктлары белән тәэмин итү, авылны яңарту мәсьәләсендә халык депутатларының беренче Съездында Мөрәҗәгать белән чыккан аграр депутатларның платформасын тулысы белән яклыйм.

Авыл хуҗалыгында вакыт тарафыннан сынау үткән бүгенге тотрыклы һәм ышанычлы форма —колхозлар һәм совхозларның потенциалын һәрьяклап үстерүне киләчәктә дә мөһим саныйм. Ул—игенчелекне һәм терлекчелекне үстерүгә, интенсив технологияләрне киң куллануга, фән-техника прогрессы казанышларын киң кертүгә мөмкинлек бирүче иң кулай алым. Аларга производствоны мөстәкыйль алып бару һәм камилләштерү өчен радикаль экономик реформа үткәрү хуҗалык итүнең күп төрле формаларын— аренда подрядын, фермерлар тибындагы крестьян хуҗалыкларын, кооперативларны, ассоциацияләрне, хезмәтне оештыруның һәм аңа түләүнең башка хуҗалык исәпле формаларын киң куллану мөмкинлеген ачарга кирәк. Авылда экономик мөнәсәбәтләрне тамырдан үзгәртә барып, аның хезмәтчелләренә җиргә, фермага, теләсә нинди башка тармакка тулы хокуклы хуҗа булу мөмкинлеген бирү зарури.

Социаль проблемаларны хәл итү, халыкның тормыш хәлен яхшырту өчен экономик реформаның гаять мөһимлеген исәпкә алып, республиканы региональ хуҗалык исәбенә күчерүне, һәр районның, колхозның һәм совхозның экономик мөстәкыйльлегенә ирешүне тизләтү өчен тырышачакмын. «Кем яхшырак эшли—шул яхшырак яшәргә тиеш». Бу мәсьәләдә шушы принцип тормышка ашырылырга тиеш. Аны гамәлгә ашыру максатында авылда яшәүчеләргә шәһәр халкыныкыннан калышмый торган торак һәм көнкүреш шартлары булдыру өчен үзәкләштерелгән капитал салуларның, шул исәптән промышленность предприятиеләре кору өчен бирелгән средстволарның да күпчелек өлешен авылда уңайлыклары тудырылган йортлар, балалар бакчалары, мәктәпләр, кибетләр, медицина учреждениеләре, профилакторийлар төзүгә юнәлдерү өчен актив тырышачакмын. Авылны социаль үзгәртеп коруның комплекслы программасын гамәлгә ашыру өчен, ягъни 1995 елга авылдагы торакларның кимендә яртысын газ челтәренә тоташтыру, колхозлар һәм совхозларның үзәк усадьбаларын район үзәге белән асфальт юллар белән тоташтыру, авылларны электр энергиясе белән ышанычлы һәм тотрыклы тәэмин итүгә булышу өчен тырышачакмын.

Җәмгыять средстволары исәбенә торак төзүнең күләмен киңәйтү белән беррәттән, индивидуаль йорт коручыларга җитәрлек күләмдә төзелеш материаллары бирү юлы белән кулай шартлар тудырылачак. Финанс ресурслары бүлүне арттыру һәм материаль базаларны ныгыта бару юлы белән медицина, сәүдә, культура һәм авыл хезмәтчелләренең көнкүреш хезмәте күрсәтү сфералары эшен яхшырту, аларны ягулык белән тулы тәэмин итүне алгы планга куячакмын.

Төзелеш материалларына булган дефицитны бетерүне күздә тотып төзелеш, индустрия базасын үстерүгә, кирпеч, башка төрле төзелеш материаллары эшләү производстволарының куәтләрен арттыруга булышачакмын. Фермаларда авыр кул хезмәте сорый торган процессларны механикалаштыруны тизләтүгә һәрьяклап булышуны иң актуаль бурычларның берсе итеп саныйм.

Ата-аналарның балаларын тәрбияләү белән күбрәк һәм яхшырак шөгыльләнү, яшь буынны файдалы хезмәткә тарту, культурага өйрәтү өчен мөмкинлекләрне киңәйтү максатында авылда уңай шартлар тудыруга булышлык итү турында кайгыртучанлык күрсәтәчәкмен. Мин лаеклы ялга китүчеләргә нормаль шартлар булдыруны мөһим чара итеп күрәм. Авыл пенсионерлары ягулык, шәхси маллары өчен азык, башка көнкүреш өчен кирәкле ихтыяҗлар белән беренче чиратта тәэмин ителергә тиешләр.

Азык-төлек проблемасын хәл итүне тизләтү производствоны интенсивлаштыруны таләп итә. Шуңа күрә игенчелектә һәм терлекчелектә экология тигезлеген саклаучы, тирә-юнь мохитка зыян китермәүче прогрессив технологияләрне куллануга ирешүне максат итеп куям.

Гражданнарның шәхси һәм предприятиеләрнең ярдәмче хуҗалыкларын тагын да үстерүгә булышлык итәрмен. Һәр районда, колхозда моның өчен төрле производстволар һәм промыселлар, азык һәм эшкәртү промышленносте предприятиеләре булдыру, халык кулланУы товарлары һәм туклану продуктлары җитештерүне арттыруга мөмкинлек тудырыр.

Законлылыкны, хокук тәртибен, дисциплинаны ныгытуны кичектергесез һәм мөһим эш итеп саныйм. Мин хезмәт коллективларының, милиция, прокуратура, суд, халык депутатлары Советларының ролен һәм абруен тагын да күтәрү яклы. Бу гражданнар өчен социаль гаделлекне тәэмин итәр, халыкның юридик хокукларын һәм вазифаларын гарантияләр.

Мин шулай ук республикада яшәүче барлык төр милләт вәкилләренең үзләренең туган телләрен, культурасын, милли традицияләрен үстерүгә тигез мөмкинлекләре булу өчен көрәшне мөһим саныйм, чөнки чын демократик нигездә генә халыкларның бердәй тигез һәм дус яшәвенә ирешергә, һәр милләтнең һәм халыкның һәрьяклап үсешен тәэмин итәргә мөмкин. Республикабызда ике төрле тел кертү проблемасын хәл итү өчен тырышачакмын. Татар теленә өйрәтүне кече яшьтән һәм башлангыч классларда ук башларга, аны югары педагогик дәрәҗәдә алып бару кирәк.

Сайлаучы иптәшләр!

Бүген сайлау алды платформамны тәкъдим итеп, сезгә шуны ышандыра алам: ТАССР халык депутаты итеп мине сайлаган очракта барлык көчемне, белемемне һәм тәҗрибәмне сезнең наказларыгызны үтәүгә туплаячакмын.

Бүген сөйләп кенә кала торган замана узды, һәркемнән конкрет эш, прогрессив чаралар күрү таләп ителә. Чорыбыз энергияле, халык өчен уңайлыклар тудыру мәсьәләсендә кыю хәрәкәт итүче, мәсьәләне оста куя белү һәм кискен тәнкыйтьли белү генә түгел, алда торган бурычларны практик гамәлгә ашыра алучы кешеләр кирәклеген күрсәтә. Мин үземнең программамны реаль саныйм һәм анда куелган бурычларны практик тормышка ашыру өчен бар тырышлыгымны куячакмын.

# Яшьтәш

Мәктәп балалары өчен махсус сәхифә

## Кирәкле һәм якын тел



Һәр иртәнге без ашыга-ашыга мәктәпкә барабыз. Безне нәрсә көтә анда? Һәр дәрес безнең өчен ачыш. Без кызыклы саннар дөньясында йөрибез, аннан әдипләребезнең әсәрләре белән танышабыз, туган телнең серләрен өйрәнәбез, рус теле дуслык, туганлык теле икәнен беләбез, дөньяны таныи-белергә өйрәнәбез. Фәннәр дөньясына булган сәяхәтебез авыр, әмма бик күңелле. Чөнки безнең белән янәшә күпне белүче укытучыларыбыз. Алар безнең белән дәрестә генә түгел, ә аннан тыш та бик күп эшләр эшләргә өлгерәләр.

Узган атнада мәктәптә «Рус сүзе» атналыгы үтте. Ул һәр елдагыча бик күңелле, мавыктыргыч булып узды. Рус теле гаять бай тел. Ә сүзләрнең килеп чыгу һәм куллану тарихы үзе бер зур дөнья икән. Укытучыларыбыз Флера Нәбиулловна Вәлиуллина, Гөлкәй Шамиловна Рәхмәтуллина, Гөлсинә Әнвәровна Хаҗиморатова безгә бик кызыклы сүзләр дөньясына үтеп керергә булыштылар. Анна Ахматова, Владимир Высоцкий—гаҗәеп бай сүз осталары икән бит. Алар иҗатында рус сүзе аерым бер яңарыш тапкан.

КВН, викторина, олимпиада, конкурслар безнең сүз байлыгыбызны арттыруга зур ярдәм итәләр. Үз ана телебез—татар теле булса да, рус телен теләп өйрәнәбез. Мәктәптә үткәрелгән КВНнарда, олимпиадаларда үзебезнең белемебезне тикшерәбез. 5«а» һәм 5 «б» класс укучылары да бу атнада үзләренең зирәк, өлгер икәнлекләрен күрсәттеләр. Мәсәлән, XI«б» классы укучылары Анна Ахматованың тормыш юлы һәм иҗаты буенча кичә әзерләделәр. Аларның чыгышларын укытучыларыбыз да, укучылар да бик яраттылар. Анна Ахматова иҗаты буенча үзләре кызыксынган сорауларын бирделәр.

«Рус сүзе» атналыгы бик җанлы һәм күңелле үтте.

**Л. ХӘММӘДИЕВА,**
Киекле урта мәктәбенең XI «б» класс укучысы.

Татар мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты дәресләре бирү җиңел үк түгелдер. Ләкин Кәкре Атау сигезьеллык мәктәбе укытучысы Шәмсегаян Хәбибулловна Галәветдинова укучыларында рус теленә мәхәббәт тәрбияли алган. Алай гына түгел, укучылары рус телен аның икенче туган телләре итеп таныйлар һәм аны белергә омтылалар.

—Рус язучылары әсәрләрен күбрәк укыгыз. Шул чакта сөйләм телегез шомарыр, грамматиканы үзләштерү җиңеләер,—ди ул укучыларына.

Ул мәктәптә 21 ел инде балаларга белем бирә. Бу еллар эчендә күпме укучысы аның юлын сайлады, укытучы булып җитеште.

Шәмсегаян Хәбибулловна —һәркайда көтеп алынган агитатор да. Аны җәен кыр станнарында, ындыр табакларында эшләүчеләр янында әңгәмә вакытында очратасың, ә кышын — терлекчеләр янында кунак.

Рәсемдә: Кәкре Атау мәктәбенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы Ш.Х. Галәветдинова дәрес вакытында.



*Гаилә һәм мәктәп почтасы*

## Безнең изге бурыч

Баланы намуслы, эш сөючән, Ватанга лаеклы итеп тәрбияләү— һәр ата-ананың һәм укытучының изге бурычы. Л.Н. Толстой болай дип әйткән: «Тәрбия дә, белем бирү дә бер-берсеннән аерылгысыз. Белем бирмичә генә тәрбияләп булмый, ә теләсә нинди белем тәрбияви тәэсир итә».

Чыннан да, аларны намуслы, булдыклы итеп ничек тәрбияләргә соң? Балаларыбызның киләчәген күз алдында тотып Зирекле тугызьеллык мәктәбендә үзара фикер алышу, тәҗрибә уртаклашу максатыннан ата-аналар җыелышы булып үтте. Мәктәп ул көнне бәйрәм төсе алды. Зал тулысынча укучылар көче белән бизәлде. Татар музыкасы яңгырап торды. Кичәне мәктәп директоры Ф. М. Сәгыйрова башлап җибәрде. Ул мәктәп тормышындагы үзгәрешләр һәм районда үткәреләчәк ата-аналар конференциясе турында сөйләп үтте.

Шуннан соң кичә җанлы төс алды. Укытучылар белән ата-аналар арасында укыту алымнары, тәрбия чаралары буенча әңгәмә алып барылды. Бигрәк тә: «Баланы нинди юллар белән чын кеше итеп тәрбияләп була?»—дигән сорауга җавап итеп Нурҗиһан Мотыйгулловна Якупова, Әминә Хәлиулловна Шәйхетдинова, Фатыйма Исмәгыйлевна Бәдретдиновалар теләп үз тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

Җыелышта Зирекле авылында урта мәктәп ачу проблемасы күтәрелде. Бик күп темаларга карата фикер алышулар булды. Соңыннан районда үткәреләчәк ата-аналар конференциясенә делегатлар сайланды.

**Г. ВӘЛИУЛЛИНА.**
Зирекле мәктәбе

## „Сәнгать уты“

Безнең мәктәптә 9—11 класслар өчен «Сәнгать уты» конкурсы булды. Ул монда беренче тапкыр үткәрелде. Һәр класс аерым бер сәнгать әсәрен күрсәтеп, аны якладылар.

Конкурсны ачучы XI класс рәссамы Матвеевның «Рязань Евпраксиясе» картинасын күрсәтте. Әкрен генә гитара тавышы астында җыр яңгырады. Рәсемнең тарихы турында хикәя безне Рязань җирен монгол татарлары басып алган чорларны, шул вакытта, Княгина Евпраксиянең илбасарларга бирелеп таптатырга теләмичә, үзенең бер яшьлек улын тотып тәрәзәдән сикерүен күз алдына китереп бастырды.

Жюри аларның чыгышын иң яхшы дип тапты һәм беренче урынны бирде, ә икенче урынны 9 «б» классы алды. Алар башкаруында «Экипаж—бер гаилә» җылы, күңелле җыр, җитез бию белән бергә барды. Ачык, якты төрле төстәге костюмнар җырга, биюгә тагын да ямь өстәп тордылар.

10 а класс тамашачылары игътибарына Гогольның «Ревизор» пьесасыннан бер өзек тәкъдим итте. Жюри аларның артистлыгы һәм үзенчәлекле костюмнарын билгеләп үтте һәм 3 нче урынны бирде.

Призлы урыннарны алмасалар да, башка класслар да бик кызыклы номерлар күрсәттеләр. Конкурс катнашучыларда һәм тамашачыларда уңай тәэсир калдырды.

**М. БИЛДАНОВА,**
**О. ГАВРИЛОВА,**
3 нче мәктәп укучылары.

## Бездә зачетлар

Соңгы вакытта мәктәп тормышында күп кенә үзгәрешләр булды. Әле бу, әле теге мәктәптә төрле экспериментлар үткәрелүе турында еш ишетелә. Ул—бишкөнлекләр, парлы дәресләр, зачетлар һәм башкалар.

Экспериментлар дулкыны шәһәрдәге дүртенче мәктәпне дә читтә калдырмады. Икенче чирек азагында 9—11 класс укучылары өчен математика, рус һәм совет әдәбияты, физика, химия, биология, чит тел кебек дәресләрдән беренче тапкыр зачет бирдек.

Зачетлар өчен махсус бер атна бүленде —25 еннән 29 декабрьгә кадәр. Көненә өч академик сәгатькә икешәр зачет тапшырдык. Хәзерләнеп тору өчен булачак сораулар белән алдан ук танышкан идек.

Әйтергә кирәк, укытучыларның зачет алу турындагы карарын без тискәре эмоцияләр белән кабул иткән идек. Ләкин зачетлар тапшырганнан соң фикер үзгәрде. Чөнки алар чиреклек билгеләрен тагын да ныгытырга мөмкинлек бирделәр. Аннан соң зачетларга хәзерлек безгә имтиханнарны уңышлы тапшырырга да ярдәм итәчәк.

Хәзер, тулаем алганда, укытучылар, укучылар арасында да зачетлар турында уңай фикер урнашты. Шуңа күрә һәр чиректән соң зачетлар уздырылачак.

**О. ПРОСТЯНЕЦКАЯ,**
10 нчы класс укучысы.



### Киекле мәктәбеннән язалар

## Уңышлар телибез

Безнең мәктәптә җыр, музыка яратучы укучылар күп. Тәнәфесләрдә, дәресләрдән буш вакытта әле бер класс бүлмәсеннән, әле икенчесеннән халкыбызның матур-матур көйләре агыла.

Сәлих Мәсләхович Фәссахов җитәкчелегендә «Уйнагыз, гармуннар» түгәрәге эшли башлады. Алдагы елларда онытылып, уйналмый торып тузанга баткан гармуннарның көмеш моңнары кабат яңгырый. Бу түгәрәк күбебезгә үзебезнең сәләтебезне ачарга, үстерергә ярдәм итә.

Ә инде 3«б» класс укучылары оештырган «Айгөл» ансамбленең чыгышын без һәрчак яратып каршы алабыз. Аларның репертуары торган саен үсә, байый. Халкыбызның балалар өчен язылган җырларын, дәртле биюләрен, шагыйрьләребезнең күңелле шигырьләрен бу ансамбль членнары бик матур итеп башкарырга тырышалар. Ансамбль членнары Гөлнара Хәсәншина, Лилия Кашапова, Айгөл Сафиуллина, Гөлнур Җәдитова, Лилия Гәрәева үзләренең матур чыгышлары белән авыл халкына да бик таныш.

Айгөл гармунда уйнарга өйрәнде. Бик кыска гына вакыт эчендә ул әллә ничә көйне отып та өлгерде. Аның гармун тавышы ансамбльнең чыгышын тагы да бизәбрәк җибәрде.

Мәктәптә үткәрелгән үзешчән сәнгать смотрында «Айгөл» ансамбле җиңүче дип табылды. Смотр дәвам итә. Алда—зона ярышлары. Анда «Уйнагыз, гармуннар» түгәрәге членнарына һәм «Айгөл» ансамбленә уңышлар телибез.

**Г. ГАЛЛӘМОВА.**
Киекле урта мәктәбе

## Ярдәмгә ашыгыгыз

Безнең Киекле урта мәктәбендә бик матур бер традиция яши. Һәр яңа уку елы башында тимурчылар командасына яшь членнар кабул итү була.

Бу уку елында да без, 5 класс укучылары, тимурчылар сафына бастык. Шуннан тотынды да инде безнең өчен иң кызыклы эшләр.

Безнең отрядта 2 звено. Һәр ике звеноның да олы яшьтәге караучысыз калган кешеләре бар. Алар—Бибигайшә әби Садыйкова һәм Зәйтүнә әби Ногъманова.

Әбиләр шундый мөлаемнар, безнең һәр килүебезне шатланып көтеп алалар.

Малайларыбыз капка-койма ремонтласа, кызларыбыз йөгерә-йөгерә су ташый, идән-кер юалар. Ә әбиләр безгә үзләре, үткән тормышлары турында сөйлиләр.

Быел кыш бик буранлы, карлы. Шуңа күрә Марсель Галиев, Ленар Ибраһимов, Гөлнара Мәсләхова, Галия Хәйретдинова, Ләйсән Гайнуллина әбиләр янында ешрак булырга тырышалар.

Әбиләрнең йөзендә шатлык булгач, безгә дә күңелле.

Без районыбыздагы һәр пионерга мөрәҗәгать итәбез. Янәшәгездә сезнең ярдәмгә мохтаҗ кешеләр юкмы? Караучысыз калган карт, гарип кешеләр суга да тилмереп утырмыймы? Игътибар белән искә төшерегез. Андый кешеләр бар икән, аңа ярдәмгә ашыгыгыз!

**Э. САФИУЛЛИНА,**
Киекле урта мәктәбенең 5«б» класс укучысы.

*Врач киңәше*

# Шикәр диабеты

Хәзер вакытсыз инвалидлыкка чыгу, үлү очраклары тудыручы йөрәк-кан тамырлары, онкологик, нерв-психик һәм башка авырулар киң таралды. Алар арасында иң киң таралганы шикәр диабеты авыруы. Бөтендөнья сәламәтлек оешмасы (ВОЗ) мәгълүматларына караганда, аның белән 30 миллионнан артык кеше (промышленность алга киткән илләр халыкларының 2—4 проценты) чирли һәм аның тагын да күтәрелү тенденциясе күзәтелә.

Шикәр диабеты —кешеләргә борынгыдан билгеле чир. Безнең көннәргә килеп җиткән беренче документлардан күренгәнчә, авыру башлангычы 1550 елларга туры килә. Диабет — «үтә чыга» дигәнне аңлата. Бу авыруның төп симптомы зур күләмдә бәвел бүлеп чыгаруга, ягъни сыекчаның бөер аша узуына бәйле. Шул ук вакытта атаклы таҗик врачы Ибн Сина (Авиценна) шикәр диабеты белән авыраучыларның бәвелдә шикәр барлыгын билгеләде.

Диабетның килеп чыгуы һәм үсеш механизмы И. Меринг, О. Минковский, П. Лангенгоре, Л. Соболев, Г. Бантинг, Ч. Бест кебек күренекле галимнәрнең исеме белән бәйләнгән. Аларның сынаулар үткәрүләре, төрле илләрнең күп кенә галимнәренең хезмәтләре нәтиҗәсендә шикәр диабеты авыруының инсулин җитешмәү, ашказаны асты бизе Бета-клеткаларының эшчәнлеге киму нәтиҗәсендә килеп туы ачыкланды. Диабетны дәвалауда практикага инсулин кертү (1922—1927 еллар) медицина фәненең зур казанышларының берседер, мөгаен.

Инсулин һәм башка средстволарны куллану шикәр диабетын дәвалауда аерым уңышка ирешергә ярдәм итте. Инсулин куллануга кадәр бу авыру кешене еш кына үлемгә алып килде. Элек диабет чире башланудан соң кеше 5 елдан артык яши алмаган. Хәзерге вакытта регуляр төстә дәвалау алып барганда һәм махсус режимны саклаганда, диабет белән чирләүчеләрнең гомере башка кешеләрнекеннән бер дә кыска түгел. Күп кенә кешеләр 30—50 ел буена диабеттан интегәләр, шулай да профессиональ эшкә сәләтләрен саклап, тулы канлы тормыш белән яшиләр.

Әмма шикәр диабеты авыр сырхауларның берсе булып кала бирә. Авыру катлаулану, йөрәк-кан тамырлары, бавыр, күз, буыннар авыруларына бәйле төстә барганда аеруча куркыныч. Нәкъ менә авыруның шушы төре сырхауның яшьли инвалид булып калуына һәм үлеменә китерә.

Шикәр диабеты белән чирләүчедә исән кешегә караганда кан әйләнеше системасы 2—3, күз авыруы 10, кул-аяк гангренасы 20 тапкыр ешрак очрый. Диабет белән авыручылар йогышлы чирләрне, бөер, җенес функцияләре эшчәнлеге бозылу, йөклелек һәм бала тудыруны авыр кичерәләр.

Күпчелек очракта шикәр диабеты нәселдән килә. Ата-ана икесе дә әлеге чирдән интегәләр, туган балаларның 60 проценты шушы ук авырудан җәфалана. Әгәр ата-ананың берсе диабет белән чирләсә, алардан туган балаларның 22, ата-ананың берсенә авыру нәселдән күчкәндә 14, туганнан туганнарда 9 процент бала диабет белән чирли.

Тазару шикәр диабеты барлыкка килүнең мөһим факторы булып тора. Күп итеп ашаганда, бигрәк тә рацион җиңел үзләштерелә торган углеводлар һәм майга бай булганда, инсуляр аппарат тукымаларында киеренкелек туа. Ә озак вакытлар күп итеп, майга бай ризыклар белән туклансаң, инсуляр аппарат йончыга һәм шикәр диабеты авыруы башланырга мөмкин.

Шикәр диабеты белән чирләүчеләрнең 60—80 процентының үлчәү авырлыгы югары була, ә симерүчеләрнең 10—40 проценты бу авыру белән чирли.

Тикшерүчеләр балаларда һәм яшь кешеләрдә шикәр диабеты килеп чыгуга психик һәм физик имгәнүләр гаепле дип исәплиләр. Ашказаны асты бизе тулысынча зарарлану, катлаулы һәм хроник понкреатит, ашказаны асты бизе кистасы яки шеше шикәр диабеты килеп чыгуга сәбәпче булырга мөмкин.

Шикәр диабеты олы яшьтәгеләрдә күбрәк күзгала. Билгеле булганча күпчелек кешеләр бу авыру белән 60 яшьтән соң чирлиләр. Бу ашказаны асты бизенең кан белән начар тәэмин ителүенә һәм инсулин барлыкка килү кимүгә бәйле. Моннан тыш, олы яшьтәге кеше яшьләргә караганда күбрәк симерүчән була.

Шикәр диабетының төп симптомы булып бәвелнең күп бүленеп чыгуы, ябыгу, гомумән хәлсезлек, эшкә сәләтнең кимүе тора. Шикәр диабеты белән чирләүчеләрнең тиресендә фурункулезга охшаш ялкынсыну, эренле тимгелләр була, тәне кычыта. Шикәр диабеты өчен характерлы бу билгеләрдән тыш авыруны еш кына баш авыртуы борчый, ул ярсучан була, начар йоклый, аппетиты я бик яхшы, я бөтенләй булмый, кул-аяклары сызлый, йөрәге авырта, күзе начар күрә башлый. Лаборатория тикшерүләре канда һәм бәвелдә шикәр күплекне күрсәтә.

Авыру кискен төстә башлана. Бу бигрәк тә яшь кешеләрдә шулай була. Ә олы яшьтәгеләрдә шикәр диабеты әкренләп үрчи һәм авыру хәлсезлек, авыз кибү, кайбер вакытларда эчәсе килү нилектән икәнлеген белми. Берише олы яшьтәгеләрдә шикәр диабеты сиздермичә бара, аңа катлауланулардан соң гына диагноз куела.

Шикәр диабетын дәвалауда чирнең үсеш формасына карап инсулин яки шикәр киметүче препаратлы таблеткалар кулланалар.

Диабет белән чирләүче һәр кеше врач-эндокренологта диспансер учетында тора. Диспансерлау ысулы шикәр диабеты белән чирләүчеләрне актив табарга, аларны системалы күзәтеп торырга һәм дәваларга ярдәм итә.

Хәзерге вакытта иртән туклангачы, шикәр дәрәҗәсен билгеләү өчен күп кешедән кан алу юлы белән шикәр диабетына дучар булучыларны табу чаралары киң кулланыла. Беренче чиратта тикшерү әлеге авыру билгеләре булган кешеләр белән үткәрелә. Мондыйларга потенциаль диабет, симерү, гипертония белән чирләү керә.

Авыруны азып киткәнче табу, үзвакытында дәвалау төрле катлауланууларны булдырмаска булыша. Авыруларга диспансер тикшерүе үткәрү—аларның тормышын, хезмәткә сәләтен саклап калуда мөһим шарт.

Профилактик чараларга рациональ туклану, физик активлык, симерүне кисәтү һәм дәвалау керә. Рационга тиз үзләштерелүчән углеводлар булган азыкларны азрак кертү, я булмаса аларны (шикәр, варенье, кондитер әйберләре, конфетлар, каймак, май) бөтенләй кертмәү яхшырак. Яшелчә, җиләк-җимеш, сөт продуктлары куллану файдага гына. Ашау-эчүдә бу чикләүләр, беренче чиратта, шикәр диабеты авыруы нәселендә булган симерү ягына киткән атеросклероз, гипертония, шулай ук 4.500 грамм авырлыктагы бала тудырган яки йөклелеге патологик булган, аннан соң яралгы үлгән хатын-кызларга бик кирәк.

Канында һәм бәвелендә шикәр артык булган кешеләргә шунда ук участок врачына яки врач-эндокренологка мөрәҗәгать итәргә киңәш бирәбез.

**С. ПЕРМЯКОВ,**
врач-эндокренолог.

# Гражданнар игътибарына!

**Йорт төзү өчен айлар һәм бик күп көннәр кирәк. Ә ут чыкса, ул аны берничә сәгать эчендә юк итә.**

**1989 ел тәмамланды. Ул безне нәрсә белән сөендерде соң? Саннарга күз салсаң,шатланырлык урын юк. Узган ел районда 72 янгын чыкты. Статистика күрсәткәнчә, шәхси йортларда янгыннар җәмәгать һәм производство биналарындагыдан ешрак була һәм бу анда яшәүчеләрнең янгынга каршы кагыйдәләрне сакламауларыннан килә.**

Әнә Михайловка авылында яшәүче Спиридон Павлович Павлов үзе электр җылыткыч ясаган һәм аны мичкә тоташтырган. Ә якында гына тиз кабынучан материаллар булган. Янгын озак көттермәгән, кабынып киткән һәм өй тулысы белән янды.

Еш кына янгыннар мичләрне артык кыздырудан килеп чыга. Былтырның 6 декабрендә Сосновка авылында бер йорт янды. Янгынның сәбәбе мичне артык кыздырудан туган. Күп очракта янгыннар электр тоташтыргычларның төзек булмавыннан чыга. Мәсәлән, яңа ел алдыннан Кормыш поселогында торак йорт янды. Йорт хуҗалары электр үткәргечләрнең төзексезлегенә әһәмият бирмәгәннәр һәм кыска ялганыштан янгын чыга. Шуны да онытырга ярамый, һәр фатирда һәм шәхси өйдә ышанычлы «сакчы»— электр саклагыч булырга тиеш. Әлеге сакчы электр челтәрендәге кыска ялганыш яки артык кызуны кисәтә. Әгәр дә инде завод саклагычы урынына «жучок» куелган булса, янгын чыгуны көт тә тор.

Электр җылыткыч приборлардан файдалану катгый тыела. Әгәр алар кулланылса, электр челтәре төзек булырга тиеш. Тагын шунысы бар, электр җайланмаларын караучысыз калдырырга һич тә ярамый.

Бөтенроссия ирекле янгын саклаучылар җәмгыятенең район Советы 48 нче ПЧ работниклары торак йортларда янгын чыгу очрагы булмасын өчен профилактик эш алып баралар. Әмма бу эшнең уңышлы башкарылуы анда торучыларның янгынга каршы кагыйдәләрне саклауларына нык бәйләнгән.

Исегездә тотыгыз! Янгын чыгу очрагы төрле, ләкин аңа кеше үзе гаепле. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен төгәл үтәгез! Бу сезгә фатирларыгызда һәм торак йортларда хуҗалык әйберләрен уттан сакларга ярдәм итәр.

**Н. СТОЛЯРОВА,**
ВДПОның район советы председателе.

# «Күктә ниләр булмас дисең...»

## Зәкия апа ни хәлдә?

Зәкия Сәгыйдуллинаның күктән төшкәннәр белән бәйләнешкә керү факты, чыннан да, моңарчы күрелгән-ишетелгән нәрсә түгел. Шуңа да газета укучыларның аны сәерсенеп кабул итүе гаҗәп түгел, безнеңчә. Әмма уфологлар бу хәлнең булуына бернинди дә шик белдермәде һәм әле дә белдерми. Гәрчә республикада андый очраклар да булгалый. Шушы фактны авыл өстендә әледән-әле очып йөргән тәлинкәләрне күрүче авылдашлары да, билгесез объект вәкилләре булган урындагы биокыр да, башка күп дәлилләр дә дәреслэп тора.

Мәкаләдә әйтелүенчә, чит планета вәкилләре З. Сәгыйдуллинага, искечә яңа елда киләбез, дип вәгъдә биргән иде. Әлеге көннән соң без Зәкия апа янына барып, аның хәлен белештек, безгә

**Гаҗәеп хәл булып тоелган бу вакыйга Башкортстанда яшәүче Зәкия Сәгыйдуллинаның сәер объектлар белән очрашуы газета укучыларда зур кызыксыну уятты. Вакыйганың дәвамы нинди, сәер затлар иске яңа елда килергә биргән вәгъдәләрендә торганнармы? Әлеге сорауларга җавап йөзеннән бүгенге мәкаләне күчереп басабыз.**

соңгы хәбәрләрне сөйләвен үтендек.

—Унөченче декабрь көнне кич белән авылда яшәүче өлкән улыма киткән идем, —дип сөйләде ул. —Артымнан төп өйдәге, улым Ирек эзләп килде. Утынлыкта, верандада әллә нинди утлар күренде. Мөгаен, тегеләр килгәннәрдер, ди. Караңгы төшкәндә веранда тәрәзәсеннән утынлыкка күз салганда ул сары төстәге утларның биешкәнен күргән. Ул да булмый, верандадагы электр чыбыгыннан ут чаткылары очкан. Кыска ялганыш-фәлән микән диеп караса, ут югалган. Икәүләп йөгереп өйгә кайттык, әмма йортта тып-тыныч иде. Шул ук төнне, нишләптер, кинәт уянып киттем. Сәгатькә карасам, ун минуттан ике тулып килә иде. Ниндидер көч тәрәзәдән үрелеп карарга мәҗбүр итте. Тәрәзәдән өч-дүрт метр ераклыкта күз алдында утлы хәрефләр сикерешә башлады. Башта бер сүз язылды, аннан икенчесе, өченчесе. Соңгысында латин, рус хәрефләре кушылган кебек, «привет» дип русча язылган иде.

Искечә яңа елны каршы алырга минем янга бик күп кунаклар килде. Белореттан, Уфадан уфологлар, аннары үземнең якын туганнарым җыелды. Башта мин бу көнне Стәрлетамакка барырга дип уйлаган идем. Туганнар йөрмәскә кушты, алар теләсә, сине барыбер таба инде, диделәр. Шуннан өйдә генә торырга булдым. Алай-болай тавыш-тын булмады, тон тыныч үтте.

Әнә шулай Зәкия апа хәзергә бер көе генә яшәп ята, әмма теге хәлдән соң йөрәгенең бераз авыртуын әйтә. Язмышына шундый зур сынау —сәер очрашу төшкән бу хатынның рухи ныклыгына, кайберәүләрнең төрле сүзләр ишеттерүенә карамастан, бирешмәвенә сокланабыз һәм теләктәшлек белдерәбез.

Редакциягә хат язучылар мунчада Зәкия апа өстенә ябылган япманың кайда булуы белән дә кызыксыналар. Ул япма сәер кунаклар киткәч тә юк була.

Ә инде очып йөрүче тәлинкәләргә килгәндә, Яңа Юлдаш авылы кешеләре аны соңгы тапкыр 1 январь көнне күргән. Шулай булгач, тәлинкәләрнең бу төбәктә булуына, Зәкия апаның билгесез объектлар белән элемтәгә керүенә шикләнергә дә урын юк. Шуны да әйтергә кирәк, НЛОларның «җиргә сәяхәте» хәзер гадәти күренешкә әверелеп бара дияргә була. Уфологлар бүгенге көнгә дөньяда алты меңнән артык кешенең шундый объектлар белән бәйләнешкә керүе билгеле, диләр. Якын көннәрдә без газета укучыларны шундый ике бәйләнеш белән таныштырырга ниятлибез.

**Ф. ФАТКУЛЛИНА.**
**(«Кызыл таң» газетасыннан).**